СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 286**

**« 13 » ноябрь 2019 ел**

**Арча район Советының 2018 елның 13 октябрендәге 199 номерлы карары белән расланган (2019 елның 1 февралендәге 220 номерлы, 2019 елның 14 мартындагы 230 номерлы үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында**

“Мәҗбүри пенсия иминияте системасында шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 2019 елның 1 апрелендәге 48-ФЗ номерлы Федераль закон тарафыннан Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 65 статьясына үзгәрешләр кертелү сәбәпле, Арча район Советы **карар бирде**:

1. Арча район Советының 2018 елның 13 октябрендәге 199 номерлы карары белән расланган (2019 елның 1 февралендәге 220 номерлы, 2019 елның 14 мартындагы 230 номерлы үзгәрешләр белән) Арча муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Нигезләмәнең 14.3 пунктының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6) шәхси (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, шул исәптән электрон документ формасында;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http:arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль район башлыгы,
район Советы рәисе

И.Г.Нуриев